УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казан ш.

2022 елның «14» марты № 13

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указын, Татарстан

Республикасы Президентының «Коррупциягә каршы көрәш турында» федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2010 елның 30 сентябрендәге ПУ-636 номерлы указын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (кушымтада бирелә) (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Идарәнең хокук, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенә:

2.1. Идарәнең Исемлеккә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

2.2. Эштән киткәндә Идарәнең Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләгән дәүләт граждан хезмәткәрләренә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы нигезләмәләрен аңлатырга.

2.3. Әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына тапшырырга.

2.4. Әлеге боерык күчермәсен Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенә, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 03 мартындагы 14 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

**Идарә җитәкчесе** **Г.Р. Нигъмәтуллина**

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
ГХАТ идарәсенең 2020
елның 14 мартындагы 13
номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә вазыйфа биләү коррупция хәтәренә бәйле булган, вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе җитәкчесе урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлеге җитәкчесе;

хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы;

контроль-методик эш бүлеге башлыгы;

ресурслар белән тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары секторы мөдире.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе (2 берәмлек);

хокук, оештыру һәм кадрлар эше буенча әйдәп баручы киңәшче;

мәгълүмат ресурслары һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы консультанты;

контроль-методик эш бүлегенең әйдәп баручы консультанты (2 берәмлек);

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

ресурслар белән тәэмин итү һәм дәүләт сатып алулары секторының әйдәп баручы белгече.